ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2020 Олы Кайбыч ав. № 500

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Олы Кайбыч авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан ерак һәм халкы аз булган авыл пунктларына товарлар илтү белән бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 15 декабрендәге 494 номерлы карары белән расланган Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Олы Кайбыч авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан ерак һәм халкы аз булган авыл пунктларына товарлар илтү белән бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

бүлекнең 2.4. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмау».

Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүматның рәсми порталында» бастырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров